КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 февраль г.Казань № 159

Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар салган зыяннар авырлыгын киметү чараларын тормышка ашыру турында

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проектын гамәлгә ашыру һәм юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар салган зыяннар авырлыгын киметү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына аларны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә: квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10ысына кадәр, Татарстан Республикасының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча хөкүмәт комиссиясе секретариатына бу карар белән күздә тотылган чараларны тормышка ашыру турында хисап кертүне.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук «Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесенә аларны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

2023 елның 1 апреленә кадәр, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, юл-транспорт һәлакәтләре күпләп була торган урыннарны, авария хәлендәге зоналарны, юл-транспорт һәлакәтләре күпләп булуы мөмкин булган урыннарны һәм юл-транспорт һәлакәтләре сирәк һәм үлүчеләре булган юллар участокларын бетерү чараларын эшләүне һәм 2023 елның 1 июленә кадәр аларны бетерү буенча планлаштырылган чараларны (контрактларда

билгеләнгән сроклар кысаларында реконструкция, капиталь ремонт һәм ремонт эшләре составына кертелгән чараларны) төгәлләүне;

2023 елның 15 июленә кадәр федераль һәм төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларында юл билгесен (шул исәптән 1.14.1 «Зебра» горизонталь билгесен) яңартып бетерүне;

юл-транспорт һәлакәтләре булган участокларда тавыш эффекты бирә торган юл билгесенең күчәр сызыгын ясауны оештыруны;

2023 елның 1 маена кадәр, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, каршыга килә торган хәрәкәт полосасына чыгуга бәйле юл-транспорт һәлакәтләрен исәпкә алып, тавыш эффекты бирә торган юл билгесенең күчәр сызыгын ясау участокларын билгеләүне, 2023 елның 15 июленә кадәр планлаштырылган чараларны башкарып бетерүне;

2023 елның 1 августыннан 28 августына кадәр белем бирү оешмалары янындагы җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарында 1.14.1 «Зебра» горизонталь билгесен яңарту чараларын башкаруны;

төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт яки ремонт объектларының проект документациясен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенә карауга җибәрүне;

түбәндәгеләрне дәвам итүне:

дүрт полосалы автомобиль юлларын каршыга килә торган хәрәкәт юнәлешләрен бүлү системалары белән җиһазлау эшен, шулай ук юл аша чыгу каралмаган урында җәяүлеләрнең транспорт йөри торган урынга чыгуын чикләү өчен җәяүлеләр коймаларын урнаштыруны;

автомобиль юлларын, беренче чиратта, торак пунктларны белем бирү оешмалары, җәяүлеләр юл аша чыгу урыннары, җәмәгать транспорты тукталышлары янында, автомобиль юлларының авария була торган куркыныч участокларын ясалма яктырту урнаштыруны;

юл-төзелеш эшләре үткәрелә торган урыннарда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә, шул исәптән тавыш полосаларын, светодиодлы индикациясе булган юл билгеләрен, юл-патруль хезмәтенең патруль автомобильләре макетларын, Россия Федерациясе Хөкүмәте – Министрлар Советының «Юл хәрәкәте кагыйдәләре турында» 1993 елның 23 октябрендәге 1090 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләрен (алга таба – Юл хәрәкәте кагыйдәләре) бозуларны фотога һәм видеога төшерү комплекслары муляжларын куллануга юнәлдерелгән чаралар комплексын тормышка ашыруны.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына:

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проектының «Юл челтәре» проектының төбәк өлешен тәшкил иткән юл эшчәнлеге программаларын формалаштырганда юл хәрәкәте иминлеген арттыруга юнәлдерелгән инженерлык чараларын күздә тотарга;

белем бирү оешмалары һәм «йорт – мәктәп – йорт» балалар хәрәкәте маршрутлары буенча урам-юл челтәре янындагы җитешсезлекләрне бетерү чараларын Татарстан Республикасының юл фонды акчасы һәм муниципаль юл фондлары акчасының калган өлеше исәбеннән юл эшләре планына даими нигездә кертүне күздә тотарга;

пластик материаллар кулланып, юл билгесен төшерү күләмнәрен арттырырга;

2023 елның 1 сентябренә кадәр кабатлана торган 3.20 «Узу тыела» һәм 1.34 «Борылу юнәлеше» юл билгеләрен куеп бетерергә;

балалар төркемнәрен оештырылган рәвештә йөрткәндә көн саен автобусларны, шулай ук мәктәп автобусларын эксплуатацияләү мониторингын үткәрергә һәм атна саен кызыксынучы министрлыкларга һәм ведомстволарга алардан файдалану мөмкинлеге торышы, тизлек режимының сакланышы турында мәгълүмат бирергә;

тизлекне мәҗбүри киметтерә торган чаралар эшләү участокларын билгеләргә һәм 2023 елның 1 сентябренә кадәр аларны (шул исәптән җәяүлеләр юл аша чыгу урыннары белән берләштерелгән ясалма тигезсезлекләрне) урнаштыру планын тормышка ашырырга;

автомобиль юлларындагы җәяүлеләр җир өстеннән юл аша чыгу урыннарына, юл чатларына һәм авария участокларына якыная торган урыннарда аркылы һәм буй-буй тавыш полосалары урнаштыруны дәвам итәргә;

2023 елның 1 мартына кадәр Татарстан Республикасы территориясендә җиңел такси белән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга сала торган закон проектын әзерләү максатларында кызыксынучы министрлыклар һәм ведомстволар хезмәткәрләре арасыннан эшче төркем төзергә;

төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеге чаралары планын үтәү кысаларында тротуарлар эшләү оештырырга;

түбәндәгеләр белән:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары белән берлектә, 2023 елның 1 апреленә кадәр муниципаль юл фондлары акчасының үзләштерелми калган өлешен 2023 елда юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча беренчел чираттагы чараларны башкаруга җибәрү турындагы тәкъдимнәрне, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән килештереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

Транспорт өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел буе федераль округы буенча төбәкара территориаль идарәсе (Татарстан Республикасы) (килешү буенча) һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә:

түбәндәге автомобиль юллары участокларын төзүдә катнашучы подряд оешмалары тарафыннан йөкләр ташу таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә:

М-12 «Мәскәү – Түбән Новгород – Казан»;

«Алексеевск – Әлмәт» («Яңа Ефәк юлы»);

Түбән Кама һәм Яр Чаллы шәһәрләрен әйләнеп үтү участокларында М-7 «Волга» Мәскәү – Владимир – Түбән Новгород – Казан – Уфа (3 нче этап);

пассажирларны законсыз йөртү фактларын туктату буенча уртак профилактик чаралар үткәрүне оештырырга;

2023 елга юл эшләре программасын үтәү кысаларында мәктәп автобуслары маршрутлары уза торган автомобиль юлларының техник һәм эксплуатация күрсәткечләрен арттыру чараларын тормышка ашырырга.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

түбәдәгеләрне дәвам итәргә:

белем бирү оешмалары эшчәнлегендә «www.sakla.ru» порталында урнашты-

рылган мәгълүмати материалларны кулллануны, шулай ук мәктәп укучыларына һәм аларның ата-аналарына әлеге ресурста юл хәрәкәте иминлеге буенча олимпиадаларда һәм викториналарда катнашуны тәкъдим итүне;

«Яшь юл хәрәкәте инспекторлары» юл хәрәкәтендә имин катнашу күнекмәләрен тәрбияләү буенча бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең төбәк бүлеген үстерүне;

белем бирү оешмаларында соңгы дәресләрдә «куркынычсызлык минутлары»ын үткәрүне, шулай ук балаларга һәм ата-аналарга юлларда үз-үзеңне дөрес тоту темасы буенча белем бирүгә, шул исәптән аларның киемендә яктылыкны кире кайтара торган элементларны йөртүен һәм балаларны тотып тора торган җайланмаларны һәм куркынычсызлык каешларын файдалануга юнәлдерелгән чаралар (дәресләр, әңгәмәләр һәм инструктажлар) үткәрүне;

2023 елның 15 апреленә кадәр мәгариф оешмаларында Юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезендә индивидуаль мобиль чараларын куллану кагыйдәләре буенча дәресләр уздыруны оештыруны;

түбәндәгеләр белән:

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) һәм «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә:

шәһәр яны һәм мәктәп яны лагерьлары чаралары планында юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау һәм, «Куркынычсызлык лабораториясе» техник һәм методологик инструментларның күчмә комплексын кулланып, яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары эшчәнлеген популярлаштыру акцияләрен күздә тотарга;

«Имин көпчәк» яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары конкурсы, яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядларының профильле сменасы, «Мин яшь юл хәрәкәте инспекторларын сайлыйм» («Я выбираю ЮИД) дигән яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары форумы кебек республика чараларын үткәрергә;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнар турында Татарстан Республикасының бердәм мәгълүмат банкына кертелгән, шулай ук Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясендә исәптә торучы балигъ булмаганнарны яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган чараларда һәм программаларда катнашуга җәлеп итүне оештырырга;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә, Татарстан Республикасының яшь юл хәрәкәте инспекторлары матбугат үзәкләренең журналистлар корпусына керүче яшь юл хәрәкәте инспекторларына методик һәм гамәли ярдәм күрсәтергә;

«Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә:

белем бирү оешмаларын юл хәрәкәте иминлегенең заманча җайланмалары белән тәэмин итүне дәвам итәргә;

2023 ел дәвамында белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәшү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган

«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәшү» дәүләт программасының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» ярдәмче программасы кысаларында алынган юл хәрәкәте иминлеге җиһазларын максатчан файдалануны тикшерергә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының 2021 елның 10 августындагы 280 номерлы һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2021 елның 10 августындагы под-1023/21 номерлы уртак боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында яшь юл хәрәкәте инспекторлары хәрәкәтен үстерү концепциясе нигезендә яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары эшчәнлеген оештырырга;

яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары эшчәнлеген үстерү белән шөгыльләнүче педагоглар өчен өстәмә финанс бирүне тәэмин итәргә;

балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмаларының чаралар планында юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау һәм яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары эшчәнлеген популярлаштыру буенча акцияләр күздә тотарга;

көн саен түбәндәгеләрне контрольдә тотуны оештырырга:

мәктәп автобуслары белән балаларны оештырылган рәвештә йөртү, шул исәптән «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылган тахограф һәм борттагы навигация җайланмалары эшләве таләпләрен саклауны;

балаларның Юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезендә һәм балалар хәрәкәтенең куркынычсыз маршрут схемалары нигезендә хәрәкәт итүен;

укучыларының яктылыкны кире кайтара торган элементларны йөртүен һәм ата-аналар җыелышларында һәм сыйныф сәгатьләрендә аларны куллану кирәклеге турында искәртүне.

5. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына:

җәмәгать судьялары тарафыннан административ хокук бозулар турындагы делолар буенча карарлар күчермәләрен суд приставлары хезмәтенә бары электрон рәвештә мәҗбүри үтәүгә үз вакытында җибәрүне тәэмин итәргә;

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән берлектә, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.8, 12.26 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы делолар буенча карарларның күчермәләрен суд приставлары хезмәтенең структур бүлекчәләренә үтәүгә үз вакытында җибәрүне квартал саен чагыштырып тикшерүне оештырырга.

6. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) һәм «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә:

балаларның һәм яшүсмерләрнең массакүләм ял итү вакытында, шул исәптән балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмаларында балаларның юл-транспорт имгәнүләрен кисәтү буенча профилактик белем бирү чараларын (тематик кичәләр, уеннар, юлларда үз-үзеңне дөрес тоту күнекмәләренә интерактив өйрәтү) үткәрергә;

Татарстан Республикасының барлык муниципаль районнарында балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмаларында яшь юл хәрәкәте инспекторларының профильле сменаларын оештыру өчен ел саен финанслауны күздә тотарга;

җәйге чорда «Камский Артек» балалар һәм яшүсмерләр ялын, аларны сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру үзәге (Түбән Кама муниципаль районы) базасында «Имин көпчәк» яшь юл хәрәкәте инспекторлары конкурсының район этабы призерларының республика профильле сменасын, шулай ук яшь юл хәрәкәте инспекторларының «Мин яшь юл хәрәкәте инспекторларын сайлыйм» («Я выбираю ЮИД») дигән республика форумын үткәрүне оештырырга, ел саен әлеге чараларны оештыруны финансларга.

7. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә:

Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында гамәлгә ашырылган сервислар исемлегенә мәгариф оешмаларында (автомәктәпләрдә) Юл хәрәкәте кагыйдәләрен белүгә теоретик имтиханны тапшыруга мониторинг ясарга мөмкинлек бирә торган ярдәм программа продуктын кертү эшен дәвам итәргә һәм мәгълүматларның статистика исәбен алып баруны күздә тотарга;

«Мин – мәктәп укучысы» сервисына юл хәрәкәте иминлеге буенча контент белән тулыландыруны тәэмин итәргә һәм аны актуальләштерүне гамәлгә ашырырга, шулай ук һәр укучы өчен «йорт – мәктәп – йорт» куркынычсыз маршрутын кертү мөмкинлеген карарга.

8. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

юл-транспорт һәлакәтләре салган зыяннарны бетерүгә җәлеп ителә торган көчләрне һәм чараларны үз вакытында әзер хәлгә китерү һәм оператив чара күрү максатларында, көн саен кызыксынучы дәүләт хакимияте башкарма органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу турында оператив фараз тапшыруны оештырырга;

түбәндәгеләр белән:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, елга кимендә дүрт тапкыр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын җәлеп итеп, юл-транспорт һәлакәтләренә чара күрү буенча махсус тактик өйрәнүләр үткәрергә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) һәм «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән, белем бирү оешмаларын максималь катнаштырып, «Тормыш иминлеге өчен юлларда иминлек» темасына тормыш иминлеге нигезләре буенча дәресләр уздырырга;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, СМС-хәбәр итү юлы белән һава шартлары начараю һәм гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуның оператив фаразы

турында халыкка хәбәр итү буенча кәрәзле элемтә операторлары белән эшне дәвам итәргә.

9. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

зыян күрүчеләрне аз җиһазландырылган травма үзәкләреннән (2 һәм 3 дәрәҗә) һәм үзәк район хастаханәләреннән 1 дәрәҗә травма үзәкләренә транспорт белән алып бару өчен санитария авиациясен җәлеп итү нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар күрергә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, 2023 елның 1 сентябренә кадәр юл-патруль хезмәте хезмәткәрләре өчен «Юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү һәм ярдәм әйберләрен куллану нәтиҗәлелеге» дигән уку курсы үткәрергә;

перинаталь үзәкләрдә юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау буенча тренинглар үткәрү тәҗрибәсен дәвам итәргә.

10. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, экологик ике айлык чорында Татарстан Республикасында юл сервисы объектларының, автомобиль юлларындагы юл өчен бүлеп бирелгән полосаларның һәм юл буе полосаларының санитар-экологик торышын контрольдә тоту эшен оештырырга.

11. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) һәм «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә:

балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда тәрбияләнүчеләрне яктылыкны кире кайтара торган элементлар белән тәэмин итәргә;

өлкән яшьтәге кешеләр арасында яктылыкны кире кайтара торган элементларны таратуны оештырырга;

ведомство буйсынуындагы оешмаларда, «www.sakla.ru» порталында урнаштырылган мәгълүмати материаллардан файдаланып, өлкән яшьтәге кешеләр, өлкәннәр һәм приютларда тәрбияләнүчеләр арасында юлларда үзләрен куркынычсыз тоту кагыйдәләрен өйрәнү буенча чаралар үткәрүне оештырырга.

12. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына җитештерүчеләргә өс киемнәре (махсус өс киемнәре) һәм аяк киемнәре теккәндә, шулай ук көнкүреш әйберләре (пакетлар, сумкалар) әзерләгәндә яктылыкны кире кайтара торган материалларны куллануны тәкъдим итәргә.

13. Татарстан Республикасының «Тормыш эшчәнлеге иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, түбәндәгеләрне дәвам итәргә:

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга юлларда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен өйрәтүнең заманча белем бирү технологияләре» программасы буенча укытуны;

яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары җитәкчеләре өчен уку-укыту семинарларын үткәрүне.

14. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына:

форматын исәпкә алып, төрле социаль челтәрләрнең медиаконтентында юл

хәрәкәте иминлеге темасы буенча язмалар чыгаруны оештырырга, шулай ук язмалар астындагы комментарийларны кире элемтә ысулы буларак кулланырга;

ел дәвамында массакүләм мәгълүмат чараларында түбәндәге материалларны бастырып чыгаруны тәэмин итәргә:

Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозып, каршыга килә торган полосага чыгарга, исерек хәлдә транспорт чаралары белән идарә итәргә, тизлек режимын арттырырга һәм зур зыян сала торган башка тупас хокук бозуларны кылырга ярамау турында;

балаларның юл-транспорт имгәнүен профилактикалау буенча;

тәүлекнең караңгы вакытында яктылыкны кире кайтара торган элементлардан файдалану зарурлыгы турында;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнардан машина йөртүчеләрнең исерек хәлдә һәм идарә итү хокукы булмаган яисә мондый хокуктан мәхрүм ителгән килеш транспорт чаралары белән идарә итү фактлары турында аноним мәгълүмат алу өчен телеграм каналын популярлаштыру турында;

автомобиль юлларының сакланышы, шул исәптән транспорт чараларының авырлыгын һәм габаритын контрольдә тоту һәм юл буе полосаларыннан файдалану өчен билгеләнгән тәртипнең үтәлеше турында;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Төбәк белән идарә итү үзәге» проектын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасындагы проект офисы белән берлектә, гражданнарга социаль челтәрләрдә («ВКонтакте», «Одноклассники», «Telegram») юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү һәм алар белән аралашу эшен көчәйтергә.

15. «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә:

транспорт чараларының авырлык-габарит параметрларын үлчәгәндә контроль-күзәтчелек органнарына булышлык күрсәтергә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, уку елы дәвамында һәм балалар һәм яшүсмерләр күпләп ял иткәндә балаларның юл-транспорт имгәнүен кисәтүгә юнәлдерелгән профилактик белем бирү чараларын үткәрергә.

16. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына (килешү буенча):

Татарстан Республикасының барлык муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссияләр утырышларын әзерләүдә һәм уздыруда катнашуны дәвам итүне;

2023 елның 31 мартына кадәр узып китү кагыйдәләрен кабат бозган һәм тизлекне сәгатенә 60 километрдан арттырган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү мәсьәләләсен күтәрү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдим җибәрергә;

2023 елның 1 маена кадәр, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары белән берлектә, яктыртырга кирәк булган автомобиль юллары участокларының җирле урам-юл челтәрен билгеләргә;

«Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесенә:

җәяүлеләрнең җир өстеннән юл аша чыгу урыннарына, юл чатларына якынаю урыннарына һәм автомобиль юлларының аварияле участокларына аркылы тавыш полосаларын һәм транспорт чаралары әйләнеп каплануын булдырмау максатларында машина юлы кырые буйлап буйлы тавыш полосаларын урнаштыруны дәвам итүне;

юл хәрәкәтен оештыруга үзгәреш кертү карала торган проект документларын раслаганда тиешле проектларны һәм схемаларны Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенә килештерүгә кертүне тәэмин итүне;

М-7 «Волга» (754 км дан 771 км га кадәр, 1055 км дан 1166 км га кадәр, 1061 км дан 1166 км га кадәр), «Казан – Оренбург» (10 км дан 13 км га кадәр, 20 км дан 43 км га кадәр, 340 км дан 347 км га кадәр) һәм «Ижевскка керү юлы» (15 км дан 28 км) автомобиль юлларында, каршы килә торган транспорт агымнарын аерып, дүрт полосалы хәрәкәт итүне оештыру эшен башкаруны;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, «Казан – Буа – Ульяновск» һәм «Киров шәһәренә керү юлы» автомобиль юлларында, каршы килә торган транспорт агымнарын аерып, транспорт йөри торган урынны киңәйтү турында Россия Федерациясенең юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча хөкүмәт комиссиясенә тәкъдимнәр кертүне;

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексының 12.8, 12.26 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы делоларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча суд органнары тарафыннан салынган административ штрафларны түләтү эшен мәҗбүри характердагы чараларны һәм административ йогынты ясауны үз вакытында куллану юлы белән активлаштыруны;

Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафлар буенча бурычы 10 мең сумнан артып киткән бурычлылардан административ штрафларны түләтү эшчәнлеген, шул исәптән, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенең махсуслаштырылган машиналар куеп тору урыннарына урнаштырып, транспорт чараларына арест салу, махсус хокуктан файдалануны һәм Россия Федерациясеннән читкә чыгу хокукын чикләү юлы белән активлаштыруны;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, юл хәрәкәте өлкәсендә бозган өчен административ штрафлар түләү бурычларын үтәмәгән транспорт чаралары милекчеләренә (хуҗаларына) карата чаралар күрү, мәҗбүри үтәү өчен үтәтү документларын җибәрүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү максатларында ведомствоара эшче төркем төзүне;

«Сетевая компания» акционерлык җәмгыятенә, ясалма яктырту объектларын, светофорларны технологик тоташтыруга шартнамә төзеп, заявка бирүче тарафыннан технологик тоташтыру кыйммәте өчен түләнгәннән соң электр энергиясен бирү буенча техник чараларны үтәүне тәэмин итүне;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына:

2023 елның 15 июленә кадәр җирле әһәмиятендәге автомобиль юлларында юл билгесен (шул исәптән 1.14.1 «Зебра» горизонталь билгесен) яңартып бетерүне;

2023 елның 1 августыннан 28 августына кадәр белем бирү оешмалары янын-

дагы җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарында 1.14.1 «Зебра» горизонталь билгесен яңарту чараларын башкаруны;

2023 елның 10 декабренә кадәр 2024 елда муниципаль әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тотуга муниципаль контрактлар төзүне;

юлның нинди хәлдә булуына карап, җайга салынмый торган җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарында светофор объектлары кую яки халык күпләп җәлеп ителә торган урыннарда ясалма тигезсезлекләр эшләү чараларын гамәлгә ашыруны;

2023 елга юл эшләре программасын үтәү кысаларында мәктәп автобуслары маршрутлары уза торган автомобиль юлларының техник һәм эксплуатация күрсәткечләрен арттыру чараларын тормышка ашыруны;

җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында аварияләр булганда юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларына һәм юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча башка чараларга (ясалма тигезсезлекләрне, җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарын һәм яктырту җайланмаларын төзекләндерү, киртәләр урнаштыру, светофор белән җайга салуны оештыруһәм юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау) чыгымнарны җирле бюджет акчасыннан күздә тотуны;

җәяүлеләр юл аша чыгу урыннары буенча мәгълүмат бирүне арттыру эшен дәвам итүне, шул исәптән светодиодлы яктылык белән юл билгеләре куюны, өстәмә яктырту куллануны күздә тотуны;

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне укуга әзерләү кысаларында 2023 елның 1 сентябренә кадәр гомуми белем бирү оешмаларында беренче сыйныф укучыларын яктылыкны кире кайтара торган элементлар белән тәэмин итүне һәм аларны яңа ел бүләкләре комплектына кертүне;

барлык яшь төркемендәге халыкның игътибарын Юл хәрәкәте кагыйдәләре үтәлешенә, юл-транспорт һәлакәтләренең төп сәбәпләренә һәм алар салган зыяннарга җәлеп итеп, алар белән мәгълүмат бирү характерындагы пропаганда чараларын үткәрүне оештыруны;

ярты елга кимендә бер тапкыр, муниципаль район башлыкларын, авыл җирлекләре башлыкларын һәм балалар белем бирү оешмалары (мәктәпләр һәм балалар бакчалары) директорларын, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларын баланста тотучыларны чакырып, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссиянең киңәйтелгән утырышын үткәрүне;

муниципаль парковкаларны оештырганда аларның урнашу урыннарын һәм юл хәрәкәтен оештыру схемаларын Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе белән килештерүне;

автомобиль юллары участокларына реконструкция яки ремонт ясала торган урыннарда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә, шул исәптән тавыш полосаларын, светодиодлы индикациясе булган юл билгеләрен, Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фотога һәм видеога төшерү комплекслары муляжларын куллануга юнәлдерелгән чаралар комплексын тормышка ашыруны;

юл сервисы объектларының юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендәге законнар таләпләренә туры килмәвен билгеләгәндә бозуларны бетерү өчен объектлар милекчеләренә карата чаралар күрүне (мәгълүматны прокуратура органнарына җибәрүне);

баланста тотучылары билгеләнмәгән автомобиль юллары участокларын баланска алуны;

2023 елның 1 мартына кадәр, тиешле юл билгеләрен кулланып, индивидуаль мобиль чаралары хәрәкәтен чикләү урыннарын билгеләүне;

индивидуаль мобиль чаралары прокатын гамәлгә ашыручы оешмаларга җир кишәрлекләре бүлеп биргәндә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 ел, 5 июнь, 416 нчы карары белән расланган Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 14 апрель, 355 нче карары нигезләмәләрен исәпкә алуны;

2023 елның 1 мартына кадәр «Зур габаритлы һәм (яки) авыр йөкләрне автомобиль белән ташуга махсус рөхсәтнамәләр бирү» системасының геомәгълүмат модуленә җирле әһәмияттәге автомобиль юллары турында мәгълүмат кертүне тәэмин итүне;

судларның юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә бәйле булган, мөлкәт характерында булмаган карарларын үз вакытында үтәүне тәэмин итүне;

юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссияләр эше кысаларында:

гражданнардан машина йөртүчеләрнең исерек хәлдә һәм идарә итү хокукы булмаган яисә мондый хокуктан мәхрүм ителгән килеш транспорт чаралары белән идарә итү фактлары турында аноним мәгълүмат алу өчен телеграм каналын популярлаштыруны;

гражданнарның урам-юл челтәрен карап тоту мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрен карарга һәм кирәкле инженерлык чараларын күрүне;

автотранспорт предприятиеләрендә транспорт йөртүчеләргә автобуслар белән идарә итү өчен рөхсәт бирүне һәм автобусларның техник торышын контрольдә тотуны оештыру мәсьәләләрен карап тикшерүне;

режимлы объектларда аларның вәкилләре катнашында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу куркынычсызлыгы мәсьәләләрен карап тикшерүне;

2023 елның 1 июненә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларының рәсми сайтларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссия эшенә багышланган бүлек булдыруны күздә тотуны;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) белән берлектә:

2023 елның 1 апрелենә кадәр автомобиль юлларының авария куркынычы булган участокларын, авария хәлендәге зоналарны, юл-транспорт һәлакәтләре күпләп булуы мөмкин булган урыннарны һәм юл-транспорт һәлакәтләре сирәк һәм үлүчеләре булган юллар участокларын бетерү чараларын эшләүне һәм 2023 елның

1 июленә кадәр аларны бетерү буенча планлаштырылган чараларны (контрактларда билгеләнгән сроклар кысаларында реконструкция, капиталь ремонт һәм ремонт эшләре составына кертелгән чараларны) төгәлләүне;

автомобиль юлларын һәм юл корылмаларын төзеп, реконструкцияләп, капиталь ремонт яки ремонт ясап бетергәч, юл хәрәкәте иминлеге торышын бәяләү һәм аларны файдалануга тапшыру мөмкинлеге турында карар кабул итү максаты белән аларны тикшерүне;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә:

кварталга кимендә бер тапкыр юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссияләр рәисләренең (шул исәптән юл-транспорт һәлакәтләре урыннарыннан) чыгышлар ясавын оештыруны;

даими рәвештә район массакүләм мәгълүмат чараларына суд залыннан фотолар белән исерек хәлдә идарә иткән өчен тоткарланган машина йөртүчеләр турында мәгълүмат җибәрүне;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитетына 2023 елның 1 августына кадәр «Камский Артек» балалар һәм яшүсмерләр ялын, аларны сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру үзәге базасында юл хәрәкәте инспекторлары отрядларының ел саен үткәрелә торган профильле сменасын һәм яшь юл хәрәкәте инспекторларының «Мин яшь юл хәрәкәте инспекторларын сайлыйм» («Я выбираю ЮИД») дигән республика форумын оештыруда катнашуны.

17. Татарстан Республикасының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча хөкүмәт комиссиясе секретариатына 2023 елның 31 августына кадәр Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссияләр эшенең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүне билгеләү турында нигезләмә эшләргә һәм аны расларга.

18. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар салган зыяннар авырлыгын киметү чараларын тормышка ашыру турында» 2021 ел, 17 декабрь, 1250 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

19. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы                                        Р.К.Нигъмәтуллин